БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 07 2020 г. № 236

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын уку елына кабул итү турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, белем бирү оешмаларын уку елына оешкан төстә һәм үз вакытында әзерләү, белем бирү хезмәтләренең сыйфатын күтәрү, аларның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. 1 нче кушымта нигезендә муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын уку елына кабул итү буенча комиссия төзергә.
2. 2 нче кушымта нигезендә муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын уку елына кабул итү комиссиясе турында нигезләмәне расларга.
3. 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф оешмаларының уку елына әзерлеген бәяләү турында нигезләмәне расларга.
4. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Вакытлыча җитәкче
вазифаларын башкаручы И.С.Галимуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның «22» 01
236 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын уку елына кабул итү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | Гайнетдинов И. Ф., Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) |
| Комиссия рәисе урынбасары: | Шагаева А. Ю., «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| Комиссия секретаре: | Петров И. И., «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы урынбасары |
| Комиссия әгъзалары: | Сагдиев И. Н., Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |
| | Гарипова Э. Ф. Балтач муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча) |
| | Газизуллин Ф. Ф., җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция начальнигы урынбасары, полиция подполковнигы (килешү буенча) |
| | Нотфуллина Г. Ф., «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ методисты |
| | Салкова Э. В., Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Арча һәм Биектау районнарында территориаль бүлеге |

башлыгы (килешү буенча)

Яппаров Н. Г., Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эше идарәсе Кукмара һәм Балтач муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге районара бүлегенең өлкән инспекторы (килешү буенча)

Салихов А. Д., Таттелеком мәгълүматлар тапшыру челтәре инженеры (килешү буенча)

Сибагатуллин Ф. Х., Балтач муниципаль районының «Хуҗалык-эксплуатация хезмәте» МБУ директоры

Хәсәнов К. М., Балтач муниципаль районының «Хуҗалык-эксплуатация хезмәте» МБУнең баш инженеры

Закиров Р. Р., Балтач муниципаль районының «Хуҗалык-эксплуатация хезмәте» МБУнең куркынычсызлык техникасы буенча инженеры

Галимҗанова Г. Р., «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ методисты

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның «22» 07
236 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын уку елына кабул итү комиссиясе турында нигезләмә**

Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын оператив рәвештә уку елына әзерләү, муниципаль бюджет мәгариф оешмаларында тиешле санитария-гигиена таләпләренә, гомуми белем бирү программаларын уңышлы гамәлгә ашыруга, балаларның гомерен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән янгынга каршы куркынычсызлык таләпләренә туры килә торган шартлар тудыру максатларында эшләнде.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын уку елына кабул итү комиссиясе (алга таба - Комиссия) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә төзелде.

1.2. Муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын уку елына кабул итү комиссиясе турында әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) комиссия тарафыннан районның муниципаль бюджет мәгариф оешмаларының уку елына әзерлеген тикшерү тәртибен билгели.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләрне тикшерү тора:
- биналарның санитар-гигиена таләпләренә туры килү - килмәвен;

- җилләтүнең (вентиляциянең), җылытуның, һаваны сафландыруның (кондиционерлауның), су белән тәэмин итүнең, ташландык суларны чыгаруның, табигый һәм ясалма яктыртуның торышын;
- лицензия таләпләрен үтәүне һәм аңа туры килүне;
- ашханәнең, технологик, суыткыч җиһазларының әзерлеген;
- уку кабинетларының, күрсәтмә-уку әсбапларының әзерлеген;
- остаханәләрнең, аларның җиһазларының әзерлеген;
- спорт залларының, спорт мәйданчыкларының әзерлеген, спорт җиһазларының төзеклеген;
- медицина кабинетының әзерлеген;
- йокы корпусларының әзерлеген;
- ял бүлмәләренең, уен бүлмәләренең әзерлеген;
- территорияне төзекләндерүне, коймаларның һәм яктыртуның булу-булмавын;
- оешмалар балансында булган котельныйларның һәм насос җиһазларының әзерлеген;
- котельный операторларында уку узу турында таныклыклар булуны;
- гамәлдәге электр белән тәэмин итү чыганакларының әзерлеген;
- кирәкле медицина тикшерүләрен узу турында таныклыклар булуны;
- биналарга һәм корылмаларга планлы-кисәтү ремонтын оештыру буенча чараларны әзерләү планын;
- уку елы башына кирәкле документларны;
- 2020-2021 уку елына мәгариф оешмасының эш планын;
- ачыкланган вакансияләр буенча кадрларны урнаштыруны;
- педагогик хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү планын;
- янгын куркынычсызлыгы, хезмәтне саклау һәм оешмаларның санитар торышы өчен җаваплы затларның боерыклары булуны;
- куркынычсызлык техникасы һәм хезмәтне саклау буенча инструктаж журналларын алып баруны;
- спорт инвентаре, җиһазлар һәм вентиляция җайланмаларын сынауланың нәтиҗәләрен теркәү журналларын алып баруны;
- хезмәт тәртибе кагыйдәләрен;
- физика, биология, остаханәләр, спорт залында эшләү мөмкинлегенә актлар-рөхсәтләр булуны һ. б.;
- хезмәткәрләргә медицина тикшерүе үткәрүне.

## 3. Комиссия составы

3.1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе карары белән Комиссия төзелә һәм состав раслана.

3.2. Комиссия составына керә:

- рәис - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча);
- рәис урынбасары - «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесе;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге вәкилләре;

- һөнәри иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр, мәгариф оешмалары, дәүләт күзәтчелек органнары, башка оешмалар вәкилләре.

3.4. Комиссия рәисе;

- комиссия эше белән җитәкчелек итә;

- комиссия утырышын билгели.

3.5. Комиссия рәисе булмаганда эш белән комиссия рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

3.6. Комиссия вәкаләтләре Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан муниципаль бюджет белем бирү оешмаларының уку елына әзерлеге актлары расланганнан соң туктатыла.

## 4. Муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын кабул итү тәртибе һәм шартлары

4.1. Бюджет белем бирү оешмаларын кабул итү Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган график нигезендә бара.

4.2. Муниципаль бюджет белем бирү оешмасының әзерлеге әзерлек паспортында чагыла һәм комиссия имзалары белән раслана.

4.3. Билгеләнгән вакытка бюджет белем бирү оешмаларының әзерлек актларын раслау турында карар кабул ителмәгән муниципаль бюджет белем бирү оешмалары уку елына әзер түгел дип танылa.

Бу очракта белем бирү оешмасының әзерлеген кабат тикшерү учреждениеләрне уку елына әзер түгел дип тану өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәннән соң, әмма агымдагы елның 24 августыннан да соңга калмыйча, башкарыла.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның «22» 07
236 номерлы карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү оешмаларының уку елына әзерлеген бәяләү турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф оешмаларының уку елына әзерлеген бәяләү турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 – ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән.

1.2. Белем бирү оешмаларын кабул итү составына килешү буенча түбәндәгеләр кергән комиссия тарафыннан башкарыла:

- рәис - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;
– рәис урынбасары - «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МБУ җитәкчесе;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге вәкилләре;
- һөнәри иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр, мәгариф оешмалары, дәүләт күзәтчелек органнары, башка оешмалар вәкилләре.

## 2. Белем бирү оешмаларын уку елына әзерлеге буенча кабул итү максатлары һәм бурычлары

2.1. Максатлар:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү оешмаларының уку елына әзерлегенә оешкан төстә бәя бирү;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының һәр белем бирү оешмасын һәм бөтен мәгариф системасын ресурслар белән тәэмин итү (оештыру, матди-техник, финанс, социаль тәэмин итү) мәсьәләләре буенча үстерүне тоткарлый торган проблемаларны ачыклау;

2.2. Бурычлар:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф оешмаларының уку елына әзерлеген тәэмин итү;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф оешмаларында белем бирү процессын оештыру өчен шартлар тудыру;
- белем бирү оешмалары тарафыннан дәүләт нормативларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;
- белем бирү оешмаларының матди-техник базасы торышын мониторинглауны тәэмин итү;
- мәгълүматлар банкын юнәлешләр буенча формалаштыру;
- белем бирү оешмалары эшчәнлеген регламентлаучы һәм җайга салучы норматив документларны әзерләү;
- матди-техник тәэмин ителеш;
- комплекслы куркынычсызлыкны тәэмин итү;
- белем бирү оешмаларының укучылар һәм тәрбияләнүчеләр белән комплектлануы.

## 3. Кабул итү алгоритмы

3.1. Муниципаль белем бирү оешмаларының уку елына әзерлеген бәяләү турында Нигезләмә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының барлык белем бирү оешмаларына җибәрелә;

3.2. Нигезләмә нигезендә белем бирү оешмасында уку елына әзерлек буенча комиссия төзелә, комиссия составы агымдагы елның 23 июненә кадәр мәгариф оешмасы җитәкчесе тарафыннан раслана.

3.3. Муниципаль белем бирү оешмаларын кабул итү комиссиясе барлык муниципаль белем бирү оешмаларын кабул итү графигы нигезендә кабул итә.

3.4. Кабул итү нәтиҗәсе әзерлек актында чагылыш таба.

3.5. Белем бирү оешмасының әзерлек акты мәгариф оешмасы җитәкчесе тарафыннан бер нөсхәдә рәсмиләштерелә, җитәкче һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

3.6. Акт мәгариф оешмасына бирелә.

## 4. Кабул итү процедурасы

4.1. Муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын кабул итү комиссиясе график буенча белем бирү оешмаларына бара һәм Нигезләмә нигезендә уку елына әзерлеккә бәя бирә.

4.2. Белем бирү оешмасы кабул итү вакытында белем бирү оешмасының уку елына әзерлеге критерийлары нигезендә документларны өйрәнү өчен комиссиягә тәкъдим итә.

4.3. Комиссия тарафыннан мәгариф оешмасының түбәндәге биналары әзерлеккә кабул ителә:

- уку сыйныфлары, төркем бүлмәләре;
- спорт, актлар һәм музыка заллары;
- азык-төлек блогы;
- шулай ук корылмалар һәм спорт корылмалары булган белем бирү оешмасы территориясе.

4.4. Белем бирү оешмасы җитәкчесе комиссиягә кабул итү вакытында мәгариф оешмасында белем бирү процессын оештыруны регламентлаучы документларны тапшыра.

4.5. Әзерлек актында комиссия кабул итү нәтиҗәләрен һәм гомуми нәтиҗәне чагылдыра:

Белем бирү учреждениесе - «кабул ителгән», белем бирү учреждениесе - «кабул ителмәгән».

4.5.1. Белем бирү оешмасы «кабул ителгән» дип санала:

- барлык устав документлары булганда;
- белем бирү оешмалары тарафыннан янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлгәндә;
- белем бирү оешмасы тарафыннан санитар-эпидемиологик нормалар таләпләре үтәлгәндә;
- белем бирү процессында катнашучыларның физик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар булганда;
- федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә укучыларны, тәрбияләнүчеләрне укыту һәм үстерү өчен матди-техник шартлар булганда.

4.5.2. Белем бирү оешмасы «кабул ителмәгән» дип санала:

- әгәр дә янгын куркынычсызлыгы, санитария законнары таләпләрен үтәмәү сәбәпле әзерлек акты имзаланмаса;
- оештыру документлары тулы күләмдә тапшырылмаса;
- спорт залының һәм спорт җиһазларының канәгатьләнмәслек торышы шартлары һәм фактлары күзәтелсә;
- сыйфатлы туклануны оештыру өчен шартлар тудырылмаса (яки бозулар күзәтелсә).

4.6. Комиссия карары нигезендә 4.5.2 пунктчасы буенча актта канәгатьләнмәслек бәя бирүнең сәбәбе күрсәтелә, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү вакыты билгеләнә, ведомствоара комиссия тарафыннан мәгариф оешмасын кабат кабул итү датасы билгеләнә.

## 5. Белем бирү оешмасын кабул итү нәтиҗәләре

5.1. Белем бирү оешмасының уку елына әзерлеген бәяләү нәтиҗәләре мәгариф оешмалары җитәкчеләренә җиткерелә.